**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
от 09.04.2020

КАРАР
№ ПР-69

**«Актаныш муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның муниципаль функциясен башкаруның административ регламентын раслау турында» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 апрелендәге ПР-54 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Норматив хокукый актларны гамәлдәге кануннарга туры китерү максатларында, Россия Федерациясе Торак кодексының 20 маддәсенең 4.1 өлеше нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 апрелендә кабул ителгән «Актаныш муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру муниципаль функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында»гы № ПР-54 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 3 бүлегенең 25 бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «25. Планлаштырылган тикшерүне еллык план буенча тикшерүләр уздыруның еллык планына кертү өчен түбәндәгеләрдән соң бер ел узгач нигез була:

1) дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган, күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлау турында хәбәрнамә нигезендә торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы яисә күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеге буенча башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан гамәлгә ашырыла башлау;

1.1) социаль файдаланудагы беренче наемга алынган торак йортның муниципаль реестрында, торак урыннарны наймлаучы булып торучы, эшчәнлеге тикшерелергә тиешле зат булган социаль файдаланудагы наемга алынган йортларның муниципаль реестрында исәпкә кую;

2) юридик затка, шәхси эшмәкәргә соңгы планлы тикшерү үткәрүне тәмамлау;

3) коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәтләрне) куллану нормативларын билгеләү яисә үзгәртү».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.И.Габдулхаев